ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты,
Россия, 420015, Казан ш., Пушкин ур., 56 нчы йорт,
bulat.alsu1971@yandex.ru.

Мәкаләдә татар телендә балалар телетапшыруларының тарихына кыскача күзәтү ясала, бу мәгълүмати чараның үзенчәлекләре аерып чыгарыла һәм аңа караган фәнни әдәбият системалаштырыла. Эшнең максаты булып татар телендә балалар телетапшыруларының совет дәверен кыскача тасвирлау тора. «Татарстан–Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең архив видеоматериаллары, тележурналистларның истәлекләре, шәхси архивлардагы документлар тикшеренү материалы булып хезмәт итте. Казан телестудиясендәге балалар редакциясенең туган телдә телеконтент булдыру юнәлешендә зур эш алып барганлыгы исбатланды.

**Төп төшенчәләр**: тележурналистика тарихы, татар балалар телевидениесе, «Пионерстан», «Шаян ТВ»

## Кереш

Татар телендә балалар телетапшырулары соңгы биш елда кардиналь үзгәрешләр кичерә. 2018 елның 12 ноябрендә татар телендә тәүлек буе эшли торган беренче «Шаян ТВ» балалар телеканалы оештырыла. Аның башкарма директоры, баш мөхәррире – Рамилә Сәхәбетдинова. Бүгенге көнгә «Шаян ТВ» аудиториясендә 15 миллион тамашачы исәпләнә. 20 тапшыру, меңләгән чыгарылыш, татар теленә тәрҗемә ителгән ун меңләп мультфильм һәм документаль фильмнар каналның нәтиҗәле эшчәнлеген дәлилли.

«Шаян ТВ» каналының юбилей чаралары вакытында төбәк балалар телевидениесенең элгәрге тәҗрибәсен өйрәнү кирәклеге ачыклана ([1], [2], [3], [4]). Кызганычка каршы, бу проблемага багышланган тикшеренүләр системалы алып барылмаган. Татар телевидениесе тарихына караган хезмәтләрдә региональ телевидениенең барлыкка килү чорында ук балалар редакциясе эшенең аеруча актив булуы билгеләнә. Бу вакытта Казан телевидениесе студиясендә балалар һәм яшүсмерләр аудиториясенә адресланган «Яшьлек» һәм «Пионерстан» тапшырулары эфирга чыга [4, с. 121]. Үзенең бер хезмәтендә Р.В. Даутова 1970 еллар азагы – 1980 еллар башында татар телендә «Китаплар дөньясында», «Без авылда яшибез», «Уенчыклар илендә», «Кичке әкиятләр», «Әйлән-бәйлән», «Шигъри тәлгәшләр» кебек күп кенә балалар тапшырулары булуы турында яза. «Тапшыруларның үзенчәлеге, барыннан да элек, аларны балалар алып барудан гыйбарәт иде» [2, с. 95], – ди автор. Татар телендә балалар телетапшыруларының барлыкка килү тарихы турында мәгълүматны системага салу омтылышы бу хезмәтнең фәнни яңалыгы булып тора.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Казан телестудиясе журналистларының хатирәләре, тележурналист Г.Х. Зиннәтуллинаның шәхси архивында сакланган документлар, «ТНВ» телеканалының архив материаллары тикшерү материалы буларак файдаланылды.

Тикшеренү методларының комплексыннан гомуми фәнни методлар (күзәтү, индукция, дедукция, диалектика, чагыштырмача-тарихи, системалы-структуралы) кулланылды.

## Фикер алышу

Балалар телевидениесенең ил күләмендәге тарихын өйрәнгәндә, аны чорларга бүлүдә карашлар төрлелеге күзәтелә. Мәсәлән, М. Мыгаль аны өч баскычка бүлә: «совет (1939–1990 еллар), күчеш (1990–1994 еллар) һәм яңа (1994 елдан)» [5, с. 209]. О.С. Ключевская «ике контрастлы этапка бүлү турында»гы фикергә таянып, түбәндәге мөһим дәверләрне билгели: совет дәвере (1939–1990 еллар) һәм совет чорыннан соң дәвер (1990–2020 еллар) [6, с. 334]. Бу хезмәттә татар балалар телетапшырулары тарихы өч этапка бүлеп күрсәтелә: совет (1958–1990 еллар), күчеш (1990–2018 еллар), өр-яңа (2018 елдан башлап).

Совет чорында «балалар телетапшырулары» («детское телевещание») термины кабул ителә. «Телевидениенең терминологик сүзлеге: төп

төшенчәләр һәм комментарийлар» («Терминологический словарь телевидения: основные понятия и комментарии») дигән фәнни хезмәттә бу терминның мәгънәсе болай яңгырый: «Балалар телевидениесе – тамашачыларның иң яшь буынына – мәктәпкәчә, мәктәп һәм яшүсмерләргә адресланган телепрограммалар системасы. Мондый телепрограммаларның максаты – балаларны һәм үсмерләрне тәрбияләү һәм һәрьяклы укыту. Жанрлары һәм формалары буенча балалар телевидениесенең бик күп төрләре бар: әкиятләр, публицистик программалар, маҗаралы, фәнни-фантастик һәм фәнни-популяр фильмнар, кызыклы кешеләр белән очрашулар, викториналар, конкурслар, мультфильмнар» [7]. СССРда, универсаль балалар махсус телеканаллары булмау сәбәпле, балалар өчен тапшырулар үзәк һәм төбәк каналлары челтәрендә чыга.

1939 елның 2 гыйнварыннан, ягъни Ленинград телеүзәгендә балалар өчен «Яңа ел белән!» («С Новым годом! ») тапшыруы эфирга чыккан көннән балалар телетапшыруларының тарихы башлана [8, с. 125]. Әгәр төбәк телевидениесе тарихына мөрәҗәгать итсәк, балалар өчен татар телеконтентын формалаштыру буенча эксперименталь эш Казанда, юридик статусы булмаса да, 1959 елдан бирле эшләгән Әнәс Хәсән улы Хәсәнов (1935 елда туган) истәлекләре буенча, ТАССРда балалар телетапшырулары татар телендә радиотапшырулар әзерләү буенча саллы тәҗрибә туплаган энтузиастлар ярдәме белән туган [9, 1 б.].

Әлеге талантлы журналистның татар балалар телевидениесен формалаштыруга керткән өлеше, кызганычка каршы, хәзергә кадәр тиешенчә бәяләнмәгән. Ә.Х. Хәсәновның иҗат биографиясендә Казан шәһәренең Укытучылар йортында эшләп килгән драма түгәрәгендәге дәресләре мөһим урын алып тора. Ул үзен диктор сыйфатында радиода да сынап карый. Телевидениегә ул 1959 елда Казан педагогика институтын тәмамлаганнан соң килә. 1959–1972 елларда телевидениедә тапшыру мөхәрриреннән балалар редакциясенең өлкән редакторына кадәр юл үтә, аннары Казан телестудиясенең баш редакторы була. Казан телестудиясенең рәсми ачылышы алдыннан Кече телестудиядә балалар белән беренче сынау тапшырулары әзерләү буенча җитди эш алып барыла [9, 1 б.]. Башлангыч баскычта татар балалар телевидениесе эксперименталь характерда була.

СССР җитәкчелеге, балаларны тәрбияләүдә мәгълүмати мөһимлекне аңлап, радио, кино һәм телевидение үсешенә зур игътибар бирә. О.А. Маховская раслаганча, 1920 елларның икенче яртысында А. Бандураның беренче тикшеренүләренә нигезләнгән теория совет балалар тапшыруларын формалаштыруга йогынты ясый. Кино һәм телевидение «социаль укытуга» тәэсир итә дип санала. Тапшыруны карау барышында балалар өлкәннәрнең социаль тәртибен карыйлар, бу балалар өчен телепрограммаларда кулланылган [10, с. 19].

Әнәс Хәсәнов үзенең хатирәләрендә телестудиянең беренче көннәрен болай дип искә ала: «Казанда телевидение студиясе 1959 елның ноябрь аенда ачылу көненнән үк, балалар редакциясен оештыру, аның эшен педагогик нигезләргә таянып, башлап җибәрү бурычын куйды. Бу эшкә педагогик белемле Л.С. Жукова тартылган иде, ләкин ул озак эшләмәү сәбәпле, педагогия училищесын һәм Казан педагогика институтын тәмамлаган белгеч буларак, төп эш миңа йөкләнде. Үсеп килүче яшь буынга комплекслы, күпкырлы белем бирү һәм тәрбияләү совет мәктәбенең нигез ташы булуын истә тотып, без телевидениенең эшчәнлеге дә специфик үзенчәлекләре белән шул максатка ярашлы булырга тиеш дигән фикергә килдек. Редакция каршында иҗтимагый совет оештырып, аңа Казан шәһәре мәгариф бүлеге белгечләрен, мәктәп укытучыларын, пионер оешмалары вәкилләрен җәлеп иттек. ТАССР мәгариф министры М. И. Мәхмүтов безнең белән даими элемтәдә булырга ризалыгын бирде.

Иҗтимагый совет тарафыннан расланган кварталлык эш планын төзү дөрес дип табылып, ул эшебезнең кагыйдәсенә әверелде. Балаларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып, тапшыруларның тематикасын, телен аңлаешлы итеп экранга чыгару иҗатыбызның иң мөһим принцибы булды. Һәрбер баланы актив, эшлекле шәхес итеп формалаштыру өчен, тормыш белән тыгыз бәйләнгән идея-сәяси, әхлакый, хезмәт тәрбиясен алга сөргән совет мәктәбенә ярдәм итү безнең тәрбия эшенең зур бурычы иде.

Бераз алгарак китеп, шушы урында узган гасырның 90 елларында укыту-тәрбиянең бердәм процесыннан тәрбияне читкә тибәрү, аңа игътибар бетүнең җәмгыятьтә зур регресска, фаҗигагә китерүен, укытучы абруен

юкка чыгаруын әйтәсе килә. Россия Федерациясенең Белем бирү һәм фән министры А. А. Фурсенконың, без иҗатчылар (созидатели. – *Ә. Х.*) түгел, кулланучылар тәрбияләргә тиеш, дип раславы хата булды. Кеше өчен табигый булган хезмәт икенчел рольгә калды. Ачы нәтиҗәсе мәгълүм: хәзер инде терсәк якын да - тешләп булмый. Җырлап-биеп кенә иген дә үсми, йортлар да төзелми шул. Җитештерү җайга салынмаса, нәрсә куллана аласың соң? Укучы балаларга мәктәпләрдә төпле белем алуның иң мөһим бурыч икәнлеген аңлатып, аларны илнең актив позициядә торган гражданнары итеп тәрбияләү өлкән буыннарның изге бурычы ләбаса?! Бу мәңгелек бурыч!

Балалар өчен тапшыруларны ике телдә – татарча, русча әзерләү бурычы куелды. Тапшыруларга балаларның үзләрен җәлеп итү төп мәсьәлә иде. Рус балалары тапшыруларда иркенләп сөйләшә, әңгәмәдә актив катнаша, ә менә татар балалары ана телебездә ике җөмлә дә әйтә алмый, чөнки Казанда ана теле укытылган татар мәктәпләре юк хәлендә иде. Балалар катнашмаса, ул тулы канлы тапшыру була алмый. Режиссер Халит Кумысников телестудиядән киткәч, тәҗрибәле Гали Хөсәенов миңа ярдәмгә килде. Уйлана торгач, без аның белән телестудиядә балалар пионер театры оештырып, теләк белдергән балаларны татарча сәнгатьле сөйләмгә, җырларга, биергә өйрәтү максатын куйдык. Ә моның өчен шушы эшкә алынырга теләгән энтузиастларны табу зарур иде. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Асия Хәйруллина сәнгатьле сөйләм дәресләрен уздырырга, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең баш балетмейстеры Гай Таһиров биергә өйрәтергә ризалык бирде. Музыка буенча башлангыч дәресләр үткәрүне үтенеп, композитор Әнвәр абый Бакировка мөрәҗәгать иттек. Ул да бик теләп ризалашты. Эшебез нәтиҗәле булды: берничә айдан без сайлаган балалар матур, дөрес итеп сөйләшә башладылар, җырларга, биергә өйрәнделәр. Алар инде тапшыруларга да катнаша ала иде» [9, 1–3 б.].

Татар тележурналистикасы ветераннарының истәлекләре Кече студиядә (Малая студия) совет чоры балалары белән мәгълүмати эш һәм тәрбия процессында фәнни карашларга нигезләнү омтылышының булуын раслый ([9], [11]). Тапшыруларны әзерләүгә югары һәм урта белем бирү учреждениеләреннән галимнәр һәм педагоглар, танылган режиссерлар, рәссамнар, композиторлар, хореографлар, язучылар, җырчылар, артистлар җәлеп ителә. Алар арасыннан редакция советы формалаштырыла. Балалар телепрограммалары тамашачыларның яшь буынын төрле яклап тәрбияләүгә һәм белем бирүгә юнәлтелгән була. Совет балалар телевидениесенә «социализатор, тәрбияче һәм педагог миссиясе» йөкләнә [3, с. 223].

Коммунистлар партиясенең Татарстан өлкә комитеты Казан телестудиясе алдына көндәлек балалар тапшыруларын әзерләү бурычын куя. 1960 елда кастингка ярты ел дәвамында 5 меңләп бала килгән. Балалар редакциясе хезмәткәрләре туган телләрен яхшы белгән балаларны тарту юнәлешендә даими эш алып барган. Башта Казанның 30 нчы һәм 80 нче мәктәпләре укучылары белән хезмәттәшлек итәләр, аннары авыллардан сәләтле балаларны эзләү белән шөгыльләнә башлыйлар.

Бөтен илдәге кебек үк, Татарстан төбәк телевидениесендә дә пионер тематикасы өстенлек иткән. «Пионерстан» балалар тапшыруын оештыручылар 1951 елның 6 сентябреннән үзәк телевидениедә даими эфирга чыккан «Пионерия» киножурналы тәҗрибәсенә таянганнар. Аны эшләгәндә, татар тележурналистлары тематик киңлеккә һәм жанр төрлелегенә омтылалар. Балалар телетапшырулары яшь буынның инициативасын һәм кызыксынучанлыгын формалаштыруга, иҗади сәләтләрен үстерүгә зур игътибар бирә. Тапшырулар әзерләүгә гамәли эшчәнлек тәҗрибәсе булган аерым белгечләр чакырыла. Мәсәлән, балаларны музыка дөньясы белән композитор Әнвәр Бакиров таныштыра, биергә хореограф Гай Таһиров, сәхнә сөйләме сәнгатенә Асия Хәйруллина өйрәтә. Балалар тапшыруының аерым өлешләре хезмәт күнекмәләре, спорт, физкультура әзерлеге формалаштыруга юнәлдерелгән була. Телетапшырулар челтәрен тележурналистлар мәктәп программасындагы теге яки бу предметны укыту-тематик планының графигына бәйләп куярга тырышалар. Әлеге тупланган кызыклы материалны редакция балалар газеталары һәм журналлары аша популярлаштырырга омтыла. Мәсәлән, балалар физзарядкасы комплексы «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә даими рәвештә басылып торган [9, 2–4 б.].

Беренче балалар телетапшыруларын эшләүчеләр бу мәгълүмати чараның даими чыгу графигын булдырырга омтыла. Көндәлек

һәм ял көннәре балалар тапшыруларын оештыру өчен билгеле бер закончалыклар эшләнә. Редакция яшь тамашачылар һәм аларның ата-аналары белән хат язышу эшен алып бара, ә бу исә тематиканы, тапшыруның эчтәлеген һәм композициясен төзергә ярдәм итә [9, 3 б.].

«Татар телендә балалар тапшыруларында тамашачыларның яшь үзенчәлекләрен, гыйльми күзаллауларын һәм бирелгән мәгълүматны кабул итү мөмкинлекләрен исәпкә алып әзерләнгән түбәндәге циклларны аерып чыгарырга мөмкин.

1. Мәктәпкәчә яшьтәге һәм башлангыч мәктәп балалары өчен әзерләнгән тапшырулар цикллары. Рус телендә, яки ике телдә эфирга чыккан бу төркем телетапшырулары дөньяны танып-белүгә, балаларда фәнни карашлар формалаштыруга юнәлтелгән иде:

- *«Рассказы бабушки Сони»* (рус телендә). Затлы нәселдән булган кызлар институтын тәмамлаган балалар язучысы Софья Радзиевскаяның (1892–1989) табигать дөньясы турындагы кызыклы тапшырулары бу төрнең якты сәхифәләрен тәшкил итә.
- *«Синең беренче китапларың»* (ике телдә).
- *«Тапкыр бул»* (ике телдә) Табышмаклар конкурсы.
- *«Әйберләр каян килә»* (ике телдә).

Бу циклдагы аерым тапшырулар балаларда кызыксыну, зирәклек, эстетик зәвык тәрбияләү максаты белән конкурслар белән дә төрлеләндереләләр. Мәсәлән, *«Тапкыр бул»* тапшыруында табышмаклар конкурсы үткәрелсә, *«Әйберләр каян килә»*дә төрле темага рәсем конкурсы игълан ителә иде.

2. Белем бирүнең төп баскычы сыйныфларында укучы яшүсмерләрнең сәләтләрен, характер сыйфатларын, гыйлем һәм күнекмәләрен формалаштыруны һәм камилләштерүне күздә тоткан Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен цикллар:

- *«Юный казанец»* (рус телендә).
- *«Пионерстан»* (татар телендә). Бу тапшыруны камилләштерү һәм тагын да нәтиҗәлерәк итү нияте белән, язучы Н. Исәнбәт белән киңәшеп, «Пионерстан» журналы эшләдек.
- *«Казан урамнары алар исеме белән аталган»* (ике телдә). Туган шәһәр тарихы, аның күренекле шәхесләре белән таныштыруга, туган җиргә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләүгә йөз тоткан тапшыруларның берсе.
- *«Безнең календарь».* Күренекле бәйрәмнәр, сәяси юбилейлар, пионер оешмасы көннәре, данлыклы шәхесләрнең героик тормышы һәм данлыклы эшчәнлекләре белән таныштыру аша туган халкыбыз, аның батырларын белән горурлану хисе тәрбияләүгә юнәлтелгән тапшыру.
- *«Тылсымлы телевизор күрсәтә».* Бу тапшырулар мәктәп тормышын, пионер дружиналары эшен, гаилә хәлләрен тасвирлаган инсценировкалар, скетчлар, әхлакый вакыйгалар уйналганнан соң, студиядә алар турында фикер алышу, бәя бирү максаты белән эфирга чыгалар. Алар А. Макаренконың «баланы коллективта, коллектив өчен, коллектив аша тәрбияләү» принцибын тормышка ашыруның мисалларын күрсәтүгә хезмәт итәләр.
- Үз-үзеңне тоту этикасы һәм эстетикасы, язылган һәм язылмаган кагыйдәләр турында мәгълүмат бирү, олыларга һәм кечеләргә дөрес мөнәсәбәт формалаштыру, әхлак-тәрбия проблемаларын үзәккә куйган *«Матурлык дөньясында»* тапшыруы.
- *«Рәсем сәнгатенә кереш әңгәмәләре».*
- Табигый матурлыкны танып-белү, кеше һәм табигатьнең бердәмлеге, табигатьне саклау һәм башка экологик проблемалар күтәрелгән *«Табигать кочагында хозурлыкка мәхәббәт уяту»* әңгәмәләре.
- Урта яшьтәге мәктәп балалары яратып йөргән төрле оешмаларның кызыклы тормышлары, файдалы эш-гамәлләре белән таныштыруны, яшүсмерләрнең сәләтләрен үстерүне, кызыксынуларын арттыруны максат иткән төрле чаралар: авиа-судомодельчеләр, юннатлар, яшь туристлар слетларыннан, пионер лагерьларыннан репортажлар, телеочерклар, спорт бәйрәмнәреннән трансляцияләр; Болгария, ГДР, Чехословакия пионер оешмалары белән урнаштырылган дуслык элемтәләре; музыка мәктәпләре концертлары; алдынгы укучыларның гаризаларына нигезләнеп төзелгән концертлар; телевидение аша балаларга яңа җырлар өйрәтү һәм башкалар.
- Рухи камиллек белән бергә физик ныклыкны үстерү, сәламәтлекне саклауга йөз тоткан телетапшырулар: спорт мастерлары ярдәмендә иртәнге зарядка комплексларын өйрәтү, «Яшь ленинчы» редакциясен дә җәлеп итеп, уртак хезмәт оештыру; физкультурага, спортка мәхәббәт уятып, гармонияле физик үсешнең мөһимлеген аңлату өчен, ГТО,

«Алтын алка» («Золотая шайба») футбол ярышларын оператив яктырту.

- *«Яшь шахматчылар мәктәбе»* Шахмат буенча халыкара спорт мастеры Р. Нәҗметдинов һәм мастерлыкка кандидат Н. Мөхәммәтовлар җитәкчелегендә алып барылган шахмат уеннары ярдәмендә ир һәм кыз балаларның мантыйкый фикерләвен, акыл сәләтен үстерүгә, фантазияләрен баетуга, иҗат мөмкинлекләрен киңәйтүгә, мәдәни ялларын активлаштыруга һәм төрләндерүгә ирешелде.

3. Югары сыйныф һәм чыгарылыш класс укучыларын һөнәр сайлауга һәм зур тормышка әзерләгән, күнекмәләр бирүне максат иткән олы яшьтәге мәктәп балалары өчен оештырылган тапшырулар цикллары:

- *«Матурлык дөньясында».*
- Чыгарылыш сыйныф укучыларына һөнәр сайлау, аерым югары уку йортлары белән якыннанрак таныштыру максаты белән әзерләнгән *«Олы юлга чыкканда»* махсус тапшырулары.
- *Мәктәпара уку-җитештерү комплексларыннан (УПК) репортажлар* (профориентация өчен).
- *Мәктәп янындагы хезмәт участокларында эшләүче алдынгылар турында тапшырулар.*
- *«Мәктәп программасына ярдәмгә»* (ике телдә). Татарстан Укытучылар белемен күтәрү институты хезмәткәрләре белән бергәләп оештырылган бу цикл тапшырулары укучыларга турыдан-туры матур әдәбият, физика, химия һәм башка предметлардан өстәмә белем бирү чарасы булды. Телевидениенең специфик мөмкинлекләреннән файдаланып, төрле фильмнар, Казан галимнәре, әдәбият-сәнгать әһелләренең чыгышлары мәктәп программаларының тематикасы буенча календарь срокка туры китереп күрсәтелде.
- *«Язучы сүзе».* Әдәбиятның тәрбияви, эстетик ролен күтәрү, сүз сәнгатенең әһәмиятен арттыру өчен, редакция язучыларның чыгышларын даими рәвештә алып барды. Х. Туфан, Л. Ихсанова, Җ. Тәрҗеманов, Г. Бакиров, М. Хөсәен, Б. Камалов, А. Әхмәт кадерле кунаклар булдылар. Г. Тукай, А. Алиш, Г. Гобәй, И. Туктар, Б. Рәхмәт, Ә. Кари һ.б. каләм ияләре юбилейлары да зур кызыксыну белән узды. Куйбышев районы Көек авылында А. Алишка һәйкәл салу, Казанның 89 нчы мәктәбендә Г. Ибраһимовка, 26 нчы мәктәбендә М. Җәлилгә һәйкәлләр кую республика күләмендәге вакыйга булды. Редакция бу эшләрдә актив эшчәнлек күрсәтте.
- *«Эврика».*

«Көтелмәгән очрашу», «Җыр», «Урман әкияте», «Алмагач минем – әнием», «Әти диясем килә», «Октябрь кызы», «Тылсымлы яулык» махсус сценарийлар-пьесалары буенча оригинал спектакльләр студия тарихында иң беренчеләрдән булып куелды һәм аларда балалар уйнады. Минем авторлыктагы әлеге чаралар татар телендәге балалар тапшырулары тарихына онытылмас вакыйгалар булып кереп калды.

Хезмәт юлын редакциядә башлаган журналистлар тора-бара күренекле шәхесләр булып җитештеләр. Ә. Рәшитов татар халкының күренекле шагыйре; Р. Мөхәммәдиев язучы һәм сәләтле тәнкыйтьче, депутат; Р. Туфитулова язучы, депутат; Ф. Бикмурзина республиканың халык артисткасы булды. Аларның һәрберсе Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемен йөртә.

Балалар арасыннан килеп, редакция каршында оештырылган пионер театрында башлангыч сәнгать белеме алган Э. Галәветдинова (Хамматова) студиядә диктор булып хезмәт итте, Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең мактаулы исеменә лаек булды. Хәзер ул Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты профессоры» [9, 4–11 б.].

Балалар тапшыруында катнашу кайбер балаларның киләчәк язмышын, тормыш һәм хезмәт юлын билгеләде. Алар Казан телестудиясендә эшләү, тормышларын журналистика белән бәйләү турында хыяллана башлый. Мәсәлән, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов 10 яшендә Казан телевидениесе студиясендә «Пионерстан» тапшыруының алып баручысы ролендә үзен сынап карый, беренче журналист тәҗрибәсен ала.

«Пионерстан» төбәк телевидение журналының тагын бер йолдызы Гөлнара Зиннәтуллина ([12], [13], [14]) язмышында да бу тармак зур роль уйный. Ул бу тапшыруга 1960 еллар уртасында алып баручы буларак килә. Бервакыт мәктәпкә күрше бинада гына урнашкан Татарстан телестудиясеннән өч хатын-кыз керә. Болар балалар тапшырулары режиссёры Гөлсем Билалова (Исхакова), телевидение режиссёры Флюра Бикмурзина (ТРның халык артисты), режиссёр ярдәмчесе Флора Орешина була. Алар, тапшыруларда катнашу өчен, талантлы балалар сайлыйлар, хәзергечә

әйтсәк, кастинг уздыралар. Гөлсем ханым Билаловага Гөлнараның яхшы дикциясе һәм чиста тавышы ошый, һәм ул аны туры эфирда шигырь сөйләргә чакыра. Дебют уңышлы чыга. Шуннан соң 12 яшьлек Гөлнара балалар өчен әзерләнә торган «Пионерстан» тапшыруын алып бара башлый. Бу шул заман өчен яңалык була, чөнки өлкәннәр өчен әзерләнә торган тапшыруларда да «алып баручылар» юк, яңалыкларны дикторлар укый, аларга үз фикерләрен әйтү, хәтта аны интонация белән белдерү дә тыела. Татарстан Республикасы телевидениесенә үзе яңалык булып кергән Гөлнара Хабул кызы, кайсы редакциядә эшләсә дә, яңалыклар кертә-кертә, телевидение журналистикасы өлкәсендә 42 ел хезмәт куя [12, с. 21].

Гөльнара Зиннәтуллина Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. 1970 елдан алып ул балалар тапшырулары редакциясендә: режиссёр ярдәмчесе һәм ассистенты, режиссёр, тапшырулар мөхәррире һәм алып баручысы. Редакция балалар өчен күп кенә программалар әзерли [15, 18 б.]. Бу тапшырулар шул чордагы балаларны тәрбияләүдә, республика телевидениесеннән татар телендә трансляцияләнгән балалар тапшыруларының сыйфатын яхшыртуда бик мөһим роль уйный.

1970–1978 елларда балалар тапшырулары редакциясендә татар телендә берничә тапшыру барлыкка килә, аларны өлкәннәр белән бергә балалар да алып бара башлый (режиссёр – Лилия Хәбибулловна Нигъмәтова; режиссёр ярдәмчесе – Г.Х. Зиннәтуллина). Шуңа күрә татар телен яхшы белгән талантлы, артист балалар табу бурычы килеп баса. Ул чордагы татарча балалар тапшыруларының исемлеге түбәндәгедән гыйбарәт: «Китаплар дөньясында», «Без авылда яшибез», «Кичке әкиятләр», «Әйлән-бәйлән» [3, с. 30].

1978–1983 елларда Г.Х. Зиннәтуллина режиссёры Ә. И. Зарипов булган әдәби-драматик редакциядә режиссёр ассистенты вазифасын башкара. 1983 елда Гөлнара Хабуловна кабаттан балалар редакциясенә күчә һәм режиссёр ассистенты булып, ә 1985 елдан балалар тапшырулары редакторы булып эшли башлый. Ул елларда режиссёр – Л.Х. Нигъмәтова, ә режиссёр ярдәмчесе – З.Б. Куртаева. Г. Зиннәтуллина күп кенә тапшыруларның редакторы гына түгел, идея авторы да була [11, 1 б.].

ТНВ» телеканалының 1985–1993 еллардагы архив материаллары нигезендә балалар тапшыруларының түбәндәге тематик төркемчәләрен билгеләргә мөмкин:

1) җыр, музыка сәнгате, аларның үзенчәлекләре, жанрлары белән таныштыру тапшырулары:

- «*Музыка дөньясына сәяхәт*» («*Путешествие в мир музыки*»). Текстлар авторы һәм алып баручы – музыкант Р.Ю. Абязов. Тапшыру эфирга татар телендә чыга башлый. Р. Абязов текстларны рус телендә яза, ә Г. Зиннәтуллина аларны татар теленә тәрҗемә итә. Соңыннан тапшыру, рус телле балалар аудиториясенә дә йөз тотып, ике телдә алып барыла.

- *«Музыкаль әлифба»*. Текстлар авторы һәм алып баручы Казан консерваториясе педагогы С.М. Хәбибуллин.

- «*От А до Я»* балалар музыкаль абонементы. Республика күләмендә музыка белән шөгыльләнүче талантлы балаларны мөмкин кадәр күбрәк пропагандалау, алар белән якыннан таныштыру максаты белән оештырыла, чара рус телендә генә чыга. Текстлар авторы һәм алып баручы музыка белгече С.Г. Захарова. Тапшыру дирижёр Фоат Мансуров җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Зур симфоник оркестры катнашында Казан консерваториясенең актлар залында төшерелә [16].

2) матур әдәбият, аңа мәхәббәт тәрбияләү, сүз сәнгатенең асылы, төрләре һәм жанрлары хакында мәгълүмат бирү, балаларны иҗатка тарту максаты белән эшләнгән телетапшырулар:

- «*Шигьри тәлгәшләр*». Текст авторы һәм алып баручысы Роберт Миңнуллин.

3) халкыбызның гореф-гадәтләре, традицион йолалары, милли бәйрәмнәре, традицияләре хакында мәгълүмат бирү, аларны саклау һәм дәвам итү теләге белән ясалган балалар тапшырулары.

1985 елда татар халкының борынгы йола бәйрәменә багышланган ике зур тапшыру ясала. Аларның редакторы һәм идея авторы – Г.Х. Зиннәтуллина, режиссёры – Халисә Хәкимуллина, режиссёр ассистенты – З.Б. Куртаева. Тапшырулар икесе дә Татарстанның Лаеш районы Хәерби авылында төшерелә.

- «*Карга боткасы*». Ул халкыбызның иң популяр, иң күңелле язгы бәйрәмнәренең берсе булып тора. Бу тапшыруда төп рольне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

артисты, ТАССР һәм РСФСРның халык артисты Вера Егоровна Минкина башкара.

- «*Каз өмәсе*». Кыр эшләре тәмамлангач, көз ахырында яисә кыш башында үткәрелә торган бәйрәм; казларны өмәләп эшкәртү чарасы гына түгел, ә авыл халкының матур итеп аралашу, күңел ачу чарасы да булып тора [11].“Каз өмәсе” тапшыруы ноябрь аенда Хәерби авылының өлкән агрономы Шамил Әхмәтҗанович Кушмин һәм укытучы Роза Хабуловналар йортында төшерелә. Р.Х. Кушмина, балаларны да, авыл халкын да җәлеп итеп, тапшыруны әзерләүгә һәм төшерүгә зур ярдәм күрсәтә. Казларны авылдагы барлык хуҗалыктан җыялар. Салкын ноябрь ае булуга карамастан, тапшыруны төшергәндә, өйләрендәге җиһазларны урамга чыгарып торалар [3].

- «*Кичке әкиятләр*» (1970 еллардан башлап). Телевидение дикторлары, театр артистлары һ.б. бу тапшыруны алып бара. Менә аларның кайберләре: телевидение дикторы Наилә Ногманова, Г. Камал театры артисты Хәлим Җәләлов, язучы һәм режиссёр Рабит Батулла, күчмә театры артисты Нуриәхмәт Сафин һ.б.

4) комплекслы тәрбиягә, балаларның дөньяга карашларын киңәйтүгә, яшь буынны тормышка әзерләүгә йөз тоткан телетапшырулар:

- «*Бергәләп өйрәник*». Тапшыру балаларны әйләнә-тирә дөнья, табигать, музыка, этикет кагыйдәләре һәм башка мәгълүматлар белән таныштыра.

- «*Күңелле уеннар*» («*Веселые старты*») Г. Зиннәтуллина көче белән татар һәм рус телләрендә эфирга чыга. Ул Татарстан Республикасы һәм Казан Дәүләт автоинспекциясе ярдәме белән балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтүгә багышланан [16].

Редакция балалар җыр һәм бию ансамбльләрен халыккка таныту юнәлешендә дә зур эш башкара. Бию ансамбльләре катнашында фестивальләр уза. Чаллы шәһәренең Алия Идрисовна Хафизуллина җитәкчелегендәге «*Айгөл*» балалар вокаль ансамбле турында концерт-очерк Үзәк телевидение аша татар телендә күрсәтелгән беренче балалар тапшыруы була. Ә җитәкчесе Светлана Владимировна Ишкузина булган «*Бәхетле балачак*» («*Счастливое детство*») бию ансамблен «Каз өмәсе» тапшыруына да чакыралар [11, 2 б.].

Телевидение барлык редакцияләр алдына Татарстанның төрле районнарында яшәүче халыкны, шул исәптән балаларны да мөмкин кадәр күбрәк төшереп, телевизор экраннарыннан күрсәтү бурычын куя. Моның өчен хезмәткәрләр һәр җәй күчмә телевизион станция (ПТС) белән Татарстанның төрле районнарына йөреп эшлиләр.

Һәр елны эшләнеп, эфирга чыккан «*Яңа ел әкияте*» мәдәни чарасы татар совет балалар телетапшырулары арасында үзенең самимилеге, җылылыгы белән аерым урында тора. Балалар белән эшләгәндә, Г. Зиннәтуллина үзен профессиональ алып баручы буларак та, талантлы журналист буларак та күрсәтә. Аның тапшырулары балалар телендә эшләнеп, зур кызыксыну уята, зур түземсезлек белән көтеп алына. Иҗат фантазиясе ташып торган журналист яңа тапшыруларның проектларын төзү, яңа темалар, эчтәлеккә туры килгән форма эзләү осталыгы белән хезмәттәшләрен гаҗәпләндерүдән туктамый. Аның журналистлык эшчәнлеге яшьләргә осталык мәктәбенә әверелә. Яшь талантлар Гөлнара Хабуловнаның югары рейтингка ия тапшыруларында катнашырга атлыгып торалар. Мәсәлән, «*Бергәләп өйрәник*» программасы чыгарылышларының берсендә һөнәрен күрсәткән биш яшьлек Муса Маликов тапшырудан соң бөтен республикага танылa. Хәзерге вакытта ул Европа күләмендә танылган уңышлы музыкант, җырчы, композитор. Г. Зиннәтуллина әзерләгән телетапшыруларда катнашкан балалар бүгенге көндә республикада гына түгел, ә Россия Федерациясе киңлекләрендә танылу алып, халкыбыз мәдәнияте үсешенә, аны үстерүгә һәм пропагандалауга үзләреннән зур өлеш кертә. Мәсәлән, Илшат Әминов («Татарстан – Яңа Гасыр» телекомпаниясе генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, 2019 елдан ТР Журналистлар берлеге рәисе), Венера Шәмиева (җырчы, Казан дәүләт мәдәният институты доценты) һәм башкалар.

Г. Зиннәтуллинаның республика иҗади потенциалын популярлаштырудагы эше нәтиҗәсез калмый. Мәсәлән, М. Маликовка багышланган «*Минем кечкенә дустым*» сюжеты «Сахалин-92» халыкара телевизион программалар фестиваленең балалар һәм яшүсмерләр өчен тапшырулар номинациясендә, татар телевидениесе тарихында беренче тапкыр II дәрәҗә Диплом белән бүләкләнә. Чаллы

шәһәреннән «Айгөл» балалар вокаль ансамбле турындагы концерт-очерк исә Үзәк телевидение аша татар телендә күрсәтелгән беренче балалар тапшыруы булып тарихка кереп кала.

З.Б. Куртаеваның Г. Зиннәтуллина белән хезмәттәшлек иткән елларны яктырткан истәлекләре тележурналист шәхесен төрле яктан ача: «*Музыка дөньясына сәяхәт» («Путешествие в мир музыки»)* тапшыруларында Рөстәм Абязов эфирда бик матур итеп татарча сөйләм теленә өйрәнде. «*Кичке әкиятләр*» тапшыруы балалар арасында бик популяр иде, редакциягә һәркөн йөзләп хат килә. Без аларны Гөлнара белән көчкә укып бетерә идек. Хатларны балалар да, өлкәннәр дә яза. Берзаман алып баручы Нуриәхмәт Сафинга адресланган хатта: «Шулкадәр зур буең белән балаларга әкият сөйләп йөрмәсәң инде», – дигән сүзләр бар иде. Аннары тагын бер кызык хәл истә калган. 1990 еллар башында балалар бакчаларында татар төркемнәре оештырыла башлады. Бер балалар бакчасы мөдире безгә шалтыратып шундый төркем булуын, тәрбиячеләре белән бик әйбәт татарча шигырьләр өйрәнүләрен әйтте, безне балаларны телевидение өчен төшерергә чакырды. Бик шатланып бардык. Чынлап та балалар бик тырышканнар, әмма бар да мишәр диалекты белән сөйлиләр. Соңыннан өйрәткән тәрбиячеләренең сөйләме шундый икәне ачыкланды. Гөлнара белән эшләү җиңел дә, рәхәт тә булды. Тагын бер бик нык истә калган сыйфаты: балалар аны бик яраталар, аңа нык тартылалар иде. Тормышта гел аралашып, бер-беребезгә булышып яшәдек. Быел, ягъни 2022 елда 70 яшь тулыр иде бит» [11],- дип искә ала Заһирә Куртаева.

Истәлекләр, бер яктан төрле җаваплы вазифалар башкарган Г. Зиннәтуллинаның холык сыйфатларын, үз һөнәренә мәхәббәтен ачса, икенче яктан, бик мөһим массакүләм мәгълүмати чара – телевидениенең үткән тарихы, аның үзенчәлеге, үсеш баскычлары белән таныштыралар. «Балачакта миңа үземә дә (*авт. – А.Н.*) Г. Зиннәтуллинаның тапшыру-ларында катнашырга туры килде. Язучы Р. Миңнуллин алып барган *«Шигъри тәлгәшләр»*не бигрәк тә яхшы хәтерлим, чөнки анда берничә тапкыр чыгыш ясадым. Бервакыт, авылдан килгән 6–7 бала, кичтән телестудиягә репетициягә барып, аннары Гөлнара ханым гаиләсенең Бутлеров урамындагы фатирына кайтып кундык. Ә икенче көнне тапшыруны телевидение өчен төшерүгә бардык. Гөлнара апаның балаларны чын күңеленнән яратканын тою, аларның фатирында һич тә читенсенмәвебез, ә аңа ияреп Казан шәһәрендә йөрүнең чын бәхет булганы хәзергәчә истә калган. Тапшыруны төшерү өчен, телевидениедәге зур студиянең бер өлешен алдан әзерләп куялар иде. Күрәсең, балалар тапшыруын төшергәндә, студияне тагын да матуррак итәргә тырышканнардыр. Балаларны бит күренеш үзенә тартып тормаса һәм сөйләнгән сүзнең эчтәлеге кызыксындырмаса, экраннар янына мәҗбүриләп җыеп булмый. Хәтерлим: студия идәненә төсле тукыма, ә аның өстенә пыяла куялар. Хәзерге вакытта студиядә фон төсен үзгәртергә төрле төстәге яктырткычлар да җитә, ә ул вакытта мөмкинлекләр әле бик-бик чикле. Балаларны утыртыр өчен, төрле төстәге зур кублар тезелә. Яктыртып торырга зур прожекторлар куела. Ул вакытта төшерү камералары бик зур һәм авыр, аларны этеп йөрү, мөгаен, зур көч сорагандыр. Камераларга калын кабель тоташа, шуңа күрә камераны кузгаткан чакта кабельне тартып йөрергә аерым кешеләре бар. Камералар саны 3тән дә ким түгел, төрле ракурслардан төшерәләр. Тавышны яздырырга микрофоннар эленә, аларны шигырь сөйләүче балалар янына борып күчереп йөртәләр. Өстә, ягъни икенче катта режиссёр бүлмәсе, ә аның стеналары пыяладан иде. Режиссёр тапшыруны төшергән вакытта экраннан да, шушы үтә күренмәле стенадан да күзәтеп тора күрәсең. Гөлнара Хабул кызының шунда утырганы, берничә тапкыр төшеп менгәне, микрофоннан әле теге баланың, әле бу баланың я бантигын, я күлмәген төзәтеп куярга кушканы истә калган. Казан дәүләт педагогика институты студенты булган елларымда «*Бергәләп өйрәник*» тапшыруларында «*Кызыклы математика*» рубрикасын алып бардым. Телевидениедә эшләүче кешеләр Гөлнара апа белән «Сәлам! Бергәләп өйрәник» [2, б. 2–3], – дип исәнләшәләр иде [11, 2–3 б.].

Балалар телетапшырулары камилләшкән саен, кадрлар белән тәэмин итү, аларны әзерләү проблемасы көн тәртибенә куела. Тележурналистлар туган телне камил белгән сәләтле балалар белән эшләүнең яңа формаларын эзлиләр. Әйтик, 1981 елның кышында балаларны, татар балалар тапшыруларына җәлеп итү өчен, сайлап алу буенча махсус конкурс игълан ителде. «Конкурс комиссиясенә баш режиссер К.

Газизова, баш мөхәррир Ә. Сафиуллина, өлкән мөхәррир И. Сирматов, мөхәррирләр Ф. Хәкимова һәм Р. Сибгатуллина, өлкән диктор Р. Нәбиуллин, балалар тапшыруы режиссерлары Л. Нигъмәтова һәм Х. Хәкимуллина керә. Җиңүчеләр өчен 1982 елның гыйнварыннан балалар студиясендә укулар оештырыла (дәресләрне, нигездә, Р. Нәбиуллин һәм Ф. Хәкимова алып бара). Балалар белән эшләүнең әлеге кызыклы тәҗрибәсе татар телевидениесенә балаларның активлыгын үстерергә ярдәм итеп кенә калмады, ә телевидениенең Казан студиясендә билгеле бер имидж өстәде. Аны түбәндәгечә характерларга мөмкин булыр иде: бүген эшләгәндә, без милләтнең иртәгәге көне турында уйлыйбыз» [2, с. 95–96 ]. – дип яза Р.В. Даутова.

Хәзерге вакытта балалар өчен татар телендә тапшырулар күп. 2009 елның сентябрь аеннан башлап «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе эчендә барлык балалар, үсмерләр һәм яшьләр тапшырулары «Яшь ТНВ» каналы кысаларында, ә 2018 елның 12 ноябреннән «ШАЯН ТВ» телеканалында эфирга чыга. «ШАЯН ТВ» – беренче һәм бердәнбер татар балалар телеканалы. Алар буш урында барлыкка килгән каналлар түгел.

## Тикшеренү нәтиҗәләре

Тикшеренү барышында татар балалар телетапшырулары тарихына багышланган фәнни әдәбият исемлеге ачыкланды, төбәк телевидениесе ветеран-журналистлары белән интервью тупланды, «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең телеархивы өйрәнелде (ТНВ). Татар телетапшыруларының совет чоры хезмәте татар телендәге тәүлек буе эшли торган «Шаян ТВ» беренче балалар телеканалы үсеше өчен иҗади база булуы исбатланды.

## Йомгак

Татар совет балалар телетапшырулары кече яшьтәге һәм яшүсмер балаларны этик-әхлакый, эстетик, физик яктан тәрбияләүгә, аларның дөньяга карашларын формалаштыруга һәм мәгълүматларын киңәйтүгә, тормышка әзерләүгә, милли мәдәниятебезне пропагандалауга үзеннән зур өлеш кертә. Киләчәктә бу тармакның тагын да киңәеп китеп, сыйфат үзгәрешләренә, югары казанышларына җирлек, нигез әзерли. Дөньяга сибелеп яшәгән татар халкын бергә туплап, аларны бербөтен зур милләт итеп күрсәтүче татар телевидениесе булганда, милләтебезнең киләчәге булачак.

**Әдәбият**

1. *Даутова Р. В.* Становление и развитие телевидения Татарстана (вторая половина 1950-х – 1985г.г.). Казань: Изд-во Казан. гос. ун-та, 2008. 191 с.

2. *Даутова Р. Г.* Становление и развитие национальной тележурналистики: Взгляд в преддверии юбилея татарского телевидения // Агзамовские чтения – 2018. Журналистика в цифровом формате. Сборник материалов и научных статей Международной научно-практической конференции (Казань, 15 февраля 2018 г.) / науч. ред. Е.С. Дорощук и В.З. Гарифуллин; отв. ред. М.Х. Фатыхова. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2019. С. 85–97.

3. *Мухинова Н. А., Осипова М. Д.* История становления Татарского телевидения в воспоминаниях Л. Х. Нигматовой // Гуманитарные науки в XXI веке: научный интернет-журнал. Казань: Казанский государственный архитектурно-строительный университет, 2021. № 16. С. 29–36.

4. *Фатыхова М. Х.* Редакция пропаганды Казанской студии телевидения как элемент советской идеологии // Научные ведомости Белгородского государственного университета. 2015. № 24 (221). С. 118–121.

5. *Мыгаль М.* Детское телевидение в контексте современной культуры // Международная журналистика-2014: диалог культур и взаимодействие медиа разных стран. Материалы третьей международной научно-практической конференции, г. Минск, 20 февраля 2014 года. / Под ред. Т. Н. Дасаевой. Минск: Изд. центр БГУ. С. 204–214.

6. *Ключевская О. С.* Отечественное детское телевидение: к вопросу ретроспективной периодизации // Вопросы журналистики, педагогики, языкознания, 2020. № 39 (3). С. 331–344.

7. *Егоров В.* Терминологический словарь телевидения: основные понятия и комментарии, М.: Б. и., 1995. 92 с.

8. *Когатько А. Г.* История отечественного телевидения для детей // Вестник Санкт-Петербургского университета. Сер. 9. Вып.1. Ч. 1. 2007. С. 124–129.

9. Ә. Х. Хәсәнов белән интервью // А. Б. Насибуллинаның шәхси архивыннан. Кулъязма. Казан, 2021 ел. 12 б.

10. *Маховская О. И.* Дети и телевидение: История психологических исследований и экспертизы телепрограмм для детей. Под ред. О. И. Маховской, Ф. О. Марченко. Москва: ИНФРА, 2017. 171 с.

11. З. Б. Куртаева белән интервью // А. Б. Насибуллинаның шәхси архивыннан. Кулъязма. Казан, 2021 ел. 3 б.

12. *Галимуллина Г. Х., Насибуллина А. Б.* Роль телепрограмм на татарском языке в популяризации национальной культуры на региональном телевидении // Вестник Казанского

государственного университета культуры и искусств. 2019. № 1. С. 21–26.

13. *Галимуллина Г. Х., Насибуллина А. Б.* Роль цикла передач «Яшәсен театр!» телеканала «Татарстан – Новый век» Республики Татарстан в популяризации театрального искусства // Татарика. 2021. № 17. С. 105–117.

14. *Галимуллина Г. Х., Насибуллина А. Б.* Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр – Страницы истории села Кирби. Казань: ИТЭР АН РТ, 2019. 500 с.

15. *Твоё родное телевидение* // Государственная телерадиокомпания «Татарстан» – «Татарстан» Дәүләт телерадиокомпаниясе. Юбилейное издание. Казань. 2000. 32 с.

16. Архив телерадиокомпании «Татарстан – Новый век» (ТНВ).

# ИСТОРИЯ ТАТАРСКОГО ДЕТСКОГО ТЕЛЕВЕЩАНИЯ: К ПОСТАНОВКЕ ПРОБЛЕМЫ

**Алсу Булатовна Насибуллина**,
Институт Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ,
Россия, 420015, г. Казань, ул. Пушкина, д. 56,
bulat.alsu1971@yandex.ru.

В статье систематизирована научная литература по истории татарского детского телевещания. Цель работы – кратко охарактеризовать советский этап развития татарского детского телевещания. Материалом исследования послужили воспоминания тележурналистов, архивные видеоматериалы телерадиокомпании «Татарстан – Новый век» (ТНВ). Доказано, что детская редакция Казанской телестудии вела огромную работу по созданию телеконтента на родном языке, отличающегося содержательным богатством и жанровым многообразием.

**Ключевые слова**: история тележурналистики, татарское детское телевещание, «Пионерстан», «Шаян ТВ»